Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 9 (685) 17 май 2019 ел (1440, Рамазан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

Ураза тоткан - әҗер откан

Әбү Мәлик әл-Әшгари риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: «Чыннан да, җәннәттә шундый бер йорт бар: эченнән – тышы, тышыннан эче күренә. Аллаһы Тәгалә аны йомшак сөйләшкән, кешеләрне ризыкландырган, даими ураза тоткан һәм башка кешеләр йоклаганда төнлә гыйбадәт кылганнар өчен әзерләгән» .

Бер хәбәрдә әйтелгән: “Һичшиксез, җәннәтләр дүрт кешегә гашыйк. Болар: рамазан аенда ураза тоткан, Коръән укыган, телләрен (ялган һәм шуңа охшаш яманлыклардан) саклаган, күршеләрен ашаткан кешеләр”.

Гали (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: «Һичшиксез, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Бәни Исраилдән бер пәйгамбәргә: «Кавемеңә хәбәр ит: чыннан да, бер кол минем ризалыгыма ирешү өчен берәр көн ураза тотса, мин аның гәүдәсен сәламәтләндерермен һәм әҗерен арттырырмын», – дигән вәхине җиткергән» (Али Әл-Мүттәки, «Кәнзүл Уммал», 8/447, №23587).

Саваплы мәҗлес

Чаллының «Аш-су» ресторанында шәһәрнең мәселман активы өчен зурлап ифтар мәҗлесе үткәрелде. 230 кешегә әзерләнгән мәҗлес затлы, зыялы, эчтәлекле булуы белән игътибарга лаек иде. Әлеге күркәм чара Чаллы мөхтәсибәте тарафыннан оештырылып, анда ТР мәселманнарының Диния нәзарәтеннән, күрше районнардан килгән кунаклар, шәһәр җитәкчелеге вәкилләре, имамнар, шәһәрнең мәселман активы җыелды. Чара вәгазь тыңлау белән башланып китте; имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт

Гайфуллинның сәламләү сүзеннән соң мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин да үтемле вәгазен җиткерде. Азан яңгырап, авыз ачканнан соң, ир-егетләр дә, хатын-кызлар да намаз укып алдылар. Бер табын артына күмәкләп җыелган кунаклар берсеннән-берсе тәмле ризыклар белән генә сыйланып калмыйча, рамазан ае фазыйләтләре, ураза саваплары, гомумкешелек кыйммәтләре турында затлы сүз тыңлап та хозурландылар.

Яңа мәчет

Рамазан аеның 6нчы көнендә Актаныш районында яңа мәчет ачылды. “Наил” дип исем кушылган Аллаһ йорты Татарстанның Башкортостан ягыннан символик капкалары буларак кабул ителә, чөнки ул ике республиканың нәкъ чигендә урнашкан иң беренче мәчет. Аның рәсми ачылышында мәртәбәле кунак буларак Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Актанышта аны муниципаль район башлыгы Энгель Нәвапович Фәттахов һәм имам-мөхтәсиб Руслан хәзрәт Мортазин каршыладылар. Тантанага килгән дин кардәшләрне сәламләү сүзендә республика мәселманнары башлыгы рамазан аеның фазыйләтләре турында сөйләде. Үзенең чыгышын мөфти хәзрәтләре “Наил” мәчетен һәм районда тагын ике мәчет салган бертуганнар Ринат һәм Илшат Нуртдиновларга үзенең ихлас рәхмәтләрен җиткереп тәмамлады. “Наил” Актаныш мөхтәсибәтендә 55нче мәчет булып эшләп китте.

Тантана мәчеттә беренче ахшам намазы һәм ифтар ашы белән дәвам итте.

Чаллы яңалыклары

12 май көнне Чаллының Сидоровка бистәсендә урнашкан “Ихлас” мәчетендә ТР МДН тарафыннан булдырылган “Ислам. Беренче адымнар” программасы буенча белем алган укучыларның беренче чыгарылышы булып узды. Биш дәрес эчендә Ислам дине нигезләре белән танышкан шәкертләрне котларга шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин чакырылган иде. Ул шәкертләрне укуны уңышлы тәмамлаулары белән тәбрикләде. Укучыларга шәһадәтнамәләр һәм бүләкләр, ә аларга белем биргән укытучыларга рәхмәт хатлары тапшырылды.

Өйлә намазыннан соң “Ихлас” мәчетенә яңа имам-хатыйб сайланды. Әлфәс хәзрәт мәхәллә халкына Илгиз хәзрәт Сөнгатуллинны имам-хатыйб итеп билгеләргә тәкъдим итте, һәм ул бертавыштан кабул ителде.

* * *

Чаллының «Ак мәчет» мәдрәсәсендә, Рамазан ае уңаеннан, торып укучы шәкертләр арасында спорт бәйгесе уздырылды. 1 урынны - Хәйбрахманов Габделмәлик, 2 урынны - Хәмидуллин Эльвир, 3 урынны - Сәмигуллин Мөхәммәд яулады. Барлык катнашучылар татлы ризыклар белән бүләкләнде.

* * *

Рамазан – ул бәрәкәт ае. Бу айда Аллаһ үз рәхмәте белән колачлый, кимчелек-хаталарны кичерә, кылган догаларны кабул итә. Бу айда Аллаһ изгелек кылуда үзара ярышуларыгызга карый һәм исемнәрегезне фәрештәләр янында искә ала.

Аллаһның рәхмәте белән, “Хәят” мәслимәләр оешмасы быел да туташлар, ялгыз һәм мохтаҗ ханымнар өчен ифтар мәҗлесләре уздыра. Ифтарлар 27 нче бистәдә урнашкан “Хәләл Үзәктә” уза. Хәләл үзәк хуҗасы Илдар хәзрәт Зияровка ифтар өчен барлык шартлар тудырганы өчен Аллаһның рәхмәтләре булсын. Шулай ук ифтар уздыруга матди ярдәм күрсәткән мәслим-мәслимәләребезгә дә Аллаһның әҗер саваплары язылсын.

Ифтар мәҗлесләрендә катнашырга теләүчеләр, ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр өчен телефон номеры 89172243068. Ифтарлар барышында Коръән уку, вәгазь тыңлаудан тыш, төрле белгечләр белән очрашулар каралган. Алар яулыкны оста итеп бәйләү, фитнес, медицина темаларына төрле мастер-класслар уздырачак. Ифтар кичәләренә көн саен 20-25 туташ, ханымнарны чакыру күздә тотыла. Шул исәптән югарыда язылган телефон номеры буенча шалтыратып я WhatsApp аша алдан язылу сорала.

КАДЕР КИЧӘСЕ

Әбүбәкер Әбдиев, Чаллының
“Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.

Рамазан аеның соңгы ун көне эчендә Аллаһы Тәгалә җир йөзенә һәр кешенең тәкъдире белән хисапсыз фәрештәләрен җибәрә. Шушы ун көн эчендә Кадер кичәсе дигән бер төн бар. Мин сезгә бу Кадер кичәсенең хикмәте турында сөйләп үтәрмен.

Без бер Аллаһка гына бөтен мактауны багышлыйбыз, иман, ислам, Коръән һәм сәламәтлек нигъмәте өчен. Аңа хәмед иң әүвәлдә һәм ахырда. Бөтен галәмнәрнең Раббысы Аллаһка безнең мактауларыбыз булсын. Аңа бөеклек күкләрдә һәм җирдә. Ул Гыйззәтле һәм Хикмәт иясе. Мин шаһәдәт китерәм - Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк һәм шаһәдәт китерәм - Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе, ул үзенең рәсүл вазифасын үтәде, һәм ул Аллаһның юлында үлгәнче хезмәт итте. Ул Аллаһка якынайта торган бөтен юлларны ачык итеп күрсәтте һәм бөтен яман эшләрдән кисәтте. Аңа һәм аңа ияргән кирам сәхабәләргә Аллаһның салаватлары һәм сәламнәре ирешсен иде.

Ий иман китерүче бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз, хакыйкый курку белән. Аллаһка тәкъва булыгыз. Тәкъвалык ул - Аллаһка буйсыну, аның әҗеренә өметләнеп һәм Аллаһның газабыннан куркып, гөнаһларны калдыру. Тәкъвалык - ул бу дөньяда һәм ахирәттә бәхет ачкычы. Тәкъвалык - ул иң зур байлык һәм тәкъва кешеләр - иң бәхетле затлар.

Аллаһ Тәгалә галәмнәрне юктан бар итте. Ул үзенең ихтыяры һәм теләге белән кайбер нәрсәләрне Үзенең чиксез хикмәте белән икенче әйберләрдән өстен куйды. Ул, Сөбхәнәһү вә Тәгалә, урыннар арасыннан - Мәккә җирлеген, кешеләр арасыннан - сөекле Пәйгамбәребезне (с.г.в.), китаплар арасынан - Коръәнне, атнаның көннәре арасыннан - җомга көнен сайласа, төннәр арасыннан, елга бер тапкыр килә торган Кадер кичен сайлады. Аллаһ Тәгалә Үзенең бөек китабында әйтте: “Раббың Үзе теләгән вә ихтыяр иткән нәрсәне юктан бар итәр”. (Касас сүрәсе, 68 аять)

Дөреслектә, Аллаһ Тәгалә Кадер кичен башка төннәр арасынан аерды, һәм аңа гына хас булган фазыйләтләр белән, аның дәрәҗәсен күтәрде, шуңа күрә Кадер киче һәрбер мөселманның йөрәгендә зур һәм әһәмиятле урын ала. Кадер кичене бөек фазыйләтләреннән - Коръән иңү. Аллаһ Тәгалә Коръәнне тулысынча беренче күктә булган “Бейтульгиззәгә” Кадер кичендә индерде, шуннан соң егерме өч ел буена Коръән “бейтульгиззәдән” җиргә иңгән.

Аллаһ Тәгалә әйтте: “Без Коръәнне мөбарәк Кадер кичәсендә, сезне газаптан кисәтер өчен индердек, Кадер кичәсендә киләсе елдагы тәкъдир хөкем ителер, Безнең әмеребез буенча. Без илчеләребезне кешеләр янына, синең Раббыңнан рәхмәт буларак җибәрәбез. Дөреслектә, Ул ишетүче, һәм белүче”. (Духан сүрәсе, 3-6 аять)

Аллаһ Тәгалә әйтте:

1. Дөреслектә, Без Коръәнне Кадер кичендә индердек.
2. Син Кадер кичене бөеклеген беләсеңме?
3. Кадер киче мең айдан хәерлерәк.
4. Кадер кичендә Җәбраил һәм башка фәрештәләр Раббыларының теләге белән, һәр кешегә билгеләнгән бер еллык тәкъдир белән иңәрләр.
5. Кадер кичәсе кояш баеганнан башлап таң атканга чаклы имин булыр.

Шулай ук Кадер кичәсенең икенче фазыйләте: Аллаһ Тәгалә аны бәрәкәтле итте: “Без Коръәнне мөбарәк Кадер кичәсендә индердек”. (Духан сүрәсе, 3 аять)

Әйе, Кадер кичәсе бәрәкәтле, чөнки шушы төндә кылынган изге гамәл, мең ай, ягъни сиксән өч ел буе кылынган изге гамәлнең әҗеренә караганда күпкә күбрәк.

Кадер кичене өченче фазыйләте: Җәбраил (г.с.) һәм башка фәрештәләр бу төндә күктән җиргә иңә. Кадер кичендә Җәбраил һәм башка фәрештәләр Раббыларының теләге белән, һәр кешегә билгеләнгән бер еллык тәкъдир белән иңәрләр.

Кадер кичене дүртенче фазыйләте: Кадер кичәсе афәтләрдән имин булыр. Кадер киче кояш баеганнан башлап таң атканга чаклы афәтләрдән имин булыр.

Кадер кичәсенең бишенче фазыйләте: Кадер кичәсендә Раббыларының теләге белән һәр кешегә билгеләнгән берьеллык тәкъдир иңә. Ягъни шушы төндә, киләсе Кадер кичәсенә хәтле булачак тәкъдир язылыр.

Кадер кичәсенең алтынчы фазыйләте: шушы төндә Аллаһ Тәгалә Үзенең чиксез рәхмәте белән, моңа кадәр булган барча гөнаһларны кичерер. “Кем Кадер кичәсен иман белән һәм Аллаһның әҗеренә өметләнеп гыйбадәттә үткәрсә, шуның моңа хәтле булган барча гөнаһлары кичерелер.” (Бохари, Мөслим).

Кадерле дин кардәшләрем! Безгә барыбызга да Кадер кичәсенең кыйммәтен белеп, шушы төнне Рамазан аеның соңгы ун төнендә эзләп, гыйбадәттә үткәрергә кирәк.

Кадер кичәсе Рамазан аеның соңгы ун төне арасындадыр. Ул төгәл билгеләнмәгән һәм ул һәр ел төрле төндә булырга мөмкин. Так санлы кичләрдә булу ихтималы күбрәк, һәм так санлы кичләр арасында Рамазанның егерме җиденче төнендә булу ихтималы тагын да күбрәк. Бер хәдистә сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: “Кадер кичәсен Рамазанның соңгы ун төне арасыннан, бигрәк тә так санлы кичләреннән эзләгез”. (Әл-Бохари).

Убей ибн Кагб (Аллаһ аңардан разый булсын) тапшыра: Аллаһ белән ант итәм, Аллаһның илчесе безгә гыйбадәт итүне әмер иткән төннең кайчан булуын мин беләм, ул Рамазанның егерме җиденче төне. (Мөслим). Һәм аңардан сорадылар: Син аны ничек белдең? Убей ибн Кагб (Аллаһ аңардан разый булсын) җавап бирде: Аллаһның Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтеп калдырган галәмәтләре буенча.

Гарәпчә Кадер кичәсе дигән сүз (Ләйләтулкадр) тугыз хәрефтән тора һәм ул сүз “Кадер” сүрәсендә өч тапкыр очрый, тугызны өчкә тапкырласак, егерме җиде чыга, һәм шулай ук Кадер сүрәсе утыз аерым сүздән язылган, егерме җиденче булып килгән бәйлек (предлог) Ләйләтулкадр дигән сүзгә әйләнеп кайта, бу Кадер кичене егерме җиденче төндә булу ихтималын арттыра. Ләкин бу төпле гыйлем түгел, бәлки туры килү генә. Моның турында атаклы галимебез ибн Гатыя (Аллаһ аңа рәхимле булсын) әйтте: “Ул гыйлемнең асылы түгел, фәкать тәфсирнең тозы”. Ягъни ашка тәме керсен өчен әзрәк тоз салу сыман, бу мәгълүмат төпле гыйлемгә бары ямь кертә.

Ни өчен соң бу кичне Аллаһ Тәгалә төгәл генә белгертмәде икән? Аның үзенә күрә хикмәтләре бар. Аның максаты – Рамазандагы һәр кичне, Кадер кичәсе шикелле, гыйбадәттә үткәреп, зур әҗер-савапка ирешүдер. Һәм шулай ук ялкау һәм тырыш кешене бер-берсеннән аерыр өчен, чөнки ул төн билгеле булса, бар кеше, хәтта ялкавы да, бер көнгә көчен табып гыйбадәттә булыр иде.

Кадерле дин кардәшләрем, Кадер кичәсен ваемсыз үткәрә күрмәгез. Рамазанның соңгы көннәре һәм төннәрендә гыйбадәтләрегезне тагын да арттырыгыз. Кадер кичәсен уяу, намазлар, Коръән укып, догалар кылып, Аллаһы Тәгаләгә истигъфар кылып үткәрегез.

Рамазан аеның соңгы ун төнендә барыбызга үрнәк булган сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) изге гамәлләрне һәм гыйбадәт кылуны тагын да арттыра иде. Гайшә (Аллаһ аннан разый булсын) әйтте: “Аллаһның илчесе Рамазанның соңгы ун көнендә, башка көннәргә караганда, тагын да зур тырышлык белән гыйбадәт кыла иде”. (Мөслим). “Аллаһның илчесе Рамазанның соңгы ун көне җитсә, үзенең хатыннарыннан читләшеп, тулысынча гыйбадәткә кереп китә иде, төннәрен намазда үткәрә иде һәм үзенең гаиләсен йокыдан торгыза иде”.

Көннәрдән бер көнне Гайшә (Аллаһ аннан разый булсын) сөекле Пәйгамбәребездән (с.г.в.) сорады: “Ий Аллаһның илчесе, әгәр дә мин Кадер кичәсенең кайсы төндә булуын белсәм, миңа шушы төндә нинди сүзләр әйтергә?” Һәм сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) җавап бирде: “Әйт: Йә Аллаһ, син гөнаһларны кичерүче һәм Син гөнаһларны кичерергә яратасың, шуңа күрә гөнаһларымны кичер”.

Бу хәдис сахих әл-Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгында китерелә. Хөрмәтле дин кардәшләрем! Дөреслектә, соңгы ун көннең төннәрен гыйбадәттә үткәрүнең максаты - Кадер кичәсенә ирешүдер. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Кем Кадер кичәсен иман белән һәм Аллаһның әҗеренә өметләнеп гыйбадәттә үткәрсә, шуның моңа хәтле кылган барча гөнаһлары кичерелер.” (Бохари, Мөслим).

Шулай ук сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Ягъни, рамазанның соңгы ун көнендә, мең айлардан хәерлерәк булган бер төн бар, кем дә кем аның хәерлегеннән мәхрүм калса, шул бәхетсез булыр”. (Бу хәдисне Әхмәд һәм ан-Насаи тапшыралар, сахих)

Йә Аллаһ! Безгә Кадер кичәсенә ирешүне насыйп итсәң иде һәм гөнаһларыбызны кичерсәң иде!

Безгә кадәр яшәгән тугры кешеләр Кадер кичәсенең әһәмиятен аңлаганнар. Алар шушы бәрәкәтле вакытны гыйбадәттә үткәрергә тырышканнар. Аларның арасында кайберләре госел белән пакьләнеп, хушбуйлар сөртеп, Кадер кичәсен Рамазан аеның соңгы ун төнендә эзли иделәр. Аллаһ аларга рәхимле булсын.

Кадерле дин кардәшләрем, тагын бер мөһим мәсьәләне исегезгә төшереп үтәсем килә. Рамазан ае ахырында фитыр сәдакасы бирелә. Фитыр сәдакасы Ураза гаете укылганчы биреп бетерелергә тиеш. Ул вакытында тапшырылмаса, кеше өстендә бурыч булып кала һәм аны кайчан да булса бирергә кирәк. Фитыр сәдакасы бирү һәр мөселманга да вәҗиб гамәлләрдән санала. Фитыр сәдакасы мохтаҗларга бирелә. Фитыр сәдакасын мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли. Ир бала балигъ булуга, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ир-атлар өстенә төшә.

Фитырның күләменә килгәндә, ул һәрвакыт бодай, арпа, йөзем бәясе белән үлчәнгән. Уртача 2 килограмм бодай яки шуның суммасы бирелә. Мөмкинлеге булган яхшы тормышлы кешеләр җан башына 3 килограмм йөзем хисабыннан түли алалар. Гаилә башлыгы хатыны һәм балалары өчен дип сәдака бирә. Рамазан башланыр алдыннан гына бер бала туса, аның өчен дә фитыр сәдакасы бирү тиешле. Әгәр балалары үзләре эшләп акча таба яки аерым, гаилә булып яши икән, алар фитыр сәдакасын үзләре түли.

Кадерле дин кардәшләрем, Кадер кичәсен ваемсыз үткәрә күрмәгез. Рамазанның соңгы көннәре һәм төннәрендә гыйбадәтләрегезне тагын да арттырыгыз. Кадер кичәсен уяу, намазлар, Коръән укып, догалар кылып, Аллаһы Тәгаләгә истигъфар кылып үткәрегез.

СОРАУ-ҖАВАП

Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк МИННӘХМӘТОВ җавап бирә.

Сорау. Балалар бакчасына йөргән улыма прививка ясатырга кушалар, мәҗбүри диләр. Мөселман кешесенә прививка ясатырга ярыймы соң ул? Шул сорауга ачыклык кертергә булышсагыз иде.

Камилә, Чаллы шәһәре.

Җавап. Бу сорауда нинди прививка турында сүз барганы аңлашылып бетми. Мөселман табиблары яхшырак белә, алар белән киңәшләшү урынлы булыр. Мөселманнарда прививка ясатырга ярамый дигән әйбер юк.

Сорау. Еш кына, авырган вакытта, табиб билгеләгән даруларны аптекадан алам дисәң, аның күбесенең составында спирт була. Бу очракта ул даруларны кулланырга мөмкинме?

Зиннур, Чаллы шәһәре.

Җавап. Әгәр ул дару исертә торган түгел икән, аптекадан сез аны табиб кушкан дару буларак аласыз икән, аны кулланырга мөмкин. Мәзһәб буенча тыелмаган.

Уразаны боза торган һәм каза уразасы белән кәффарәтне үтәүне таләп итә торган хәлләр

Әгәр Рамазан аенда ураза тоткан кеше шул эшләрнең берәрсен белә торып һәм гозерсез эшли калса: ашаса, эчсә яки дару капса (таблетка яки сыеклык), җенси якынлык кылса, тәмәке тартса. аңа бозылган уразасын каза итеп, көнен көнгә тутырып тотарга кирәк була һәм ул кәффарәт үтәргә тиеш. Кәффарәт - Рамазан ае уразасын белә торып бозган өчен бу дөньяда бирелгән җәза. Рамазан ае уразасыннан тыш башка уразаларны бозган өчен кәффарәт үтәлми.

Кәффарәт рәттән 60 көн ураза тотудан тора. Әгәр кәффарәт өзелсә, яңабаштан 60 көнлек ураза тотарга кирәк. Кәффарәт уразасы тоткан хатыннар хәез көннәрендә аны туктатып торалар һәм бу көннәр тәмамлангач, яңадан дәвам иттерәләр.

Кемнәр җитди сәбәп белән 60 көнлек уразаны тота алмый икән, 60 фәкыйрь мөселманның тамагын туйдырырга (иртәнге һәм кичке аш ашатырга) тиешләр (тәкъвалы мөселманнарны тапсаң яхшырак була). Динсез кешеләргә кәффарәт бирелми. Ризык җитәрлек күләмдә һәм сыйфатлы булырга тиеш. Бер фәкыйрьгә 120 тапкыр иртәнге аш яисә кичке ашны ашатырга мөмкин. Яисә 60 кешегә иртәнге аш, 60 кешегә кичке ашны ашатсаң ярый.

Бирелергә тиешле ризыкның бәясен акчалата бирергә дә була. Бер фәкыйрьгә 60 көн буе яисә 60 кешегә бер көндә бирсәң була. Әгәр бөтен сумманы бер көндә бер кешегә генә бирсәң, бер көнлек кәффарәт кенә булып санала.

Әгәр кеше бер Рамазан аенда берничә тапкыр уразасын белә торып бозса (яки берничә Рамазан аенда уразасын белә торып бозса), бөтен очраклар өчен бер кәффарәт бирсә җитә.

(“Ислам дине нигезләре”ннән).

ӘДӘБИ СҮЗ

Рамазан ае

Рамазан ае мөбарәк,
Мөселманның шатлыгы.
Рухның, тәннең, акылның да
Аклыгы һәм саклыгы.

Һәр ел саен мөселманнар
Көтә аны сагынып.
Үткәрәләр гыйбадәттә,
Аллаһыга табынып.

Күз ачып йомган арада
Рамазан үтеп китә.
Аллаһыны таныганнар
Бу айны тагын көтә.

Рәзинә Мөхияр, Чаллы шәһәре.

УРАЗА ТОТУДА ТӨП ХАТАЛАР

Рамазан аен күпләр ашау-эчүдән тыелып тору белән генә бәйли. Чынлыкта исә шушы изге, фазыйләтле вакытның асыл-мәгънәсе киңрәк тә, тирәнрәк тә. Рамазанның үзенчәлекләрен, аның олуг максатын аңлап бетермәү сәбәпле, кайберәүләр әлеге гыйбадәтне кылуда хаталана, шул сәбәпле уразаларының савабы кими, ә кайчакта хаталар хәтта уразаның бозылуына да китерә. Ураза гыйбадәтенең дәрәҗәсен, кыйммәтен саклап калыр өчен еш эшләнә торган кайбер хаталарны карап чыгыйк.

Мәгълүм булганча, һәрбер гамәл ниятләр башлана.Рамазан аеның уразасын гадәттә кичтән, таң атканчы, сәхәр ашаганнан соң ниятлиләр. Кайберәүләр сәхәрне йоклап калуны сәбәп итеп, уразага кермиләр. Бу дөрес түгел: әгәр нинди дә булса сәбәп белән сәхәр ашалмыйча калса, уразаны соңрак та ниятләп куярга мөмкин (Рамазан уразасын өйлә намазына кадәр ниятләргә ярый). Әмма шуны да онытмаска кирәк: сәхәргә, аның вакытына карата ваемсыз булу һич тә дөрес түгел.

Хаталарның тагын берсе – уразаны ашказаны белән генә тотып, тәннең башка өлешләрен бу гыйбадәттә катнаштырмау: мөселманнар уразага ниятләп кергәннән соң, аяк-кулларын да, күз-колакларын һәм телен дә “ураза тоттырырга”, ягъни гөнаһлы яки гөнаһка этәрүче сүз-гамәлләрдән сакланырга тиеш. Әгәр ураза тотучы гайбәттән, начар сүзләрдән, күз зинасыннан сакланмаса, башкаларга кулы яки теле белән зыян китерсә, аның Рамазан гыйбадәте, әлбәттә, кимчелекле була.

Уразага кергәч кайберәүләр ничектер сүлпәнәеп, сүрәнләнеп китеп, көнне ялкаулыкта үткәрә, вакытны йоклап яки ниндидер файдасыз шөгыль белән уздырырга тырыша. Бу шулай ук киң таралган хаталарның берсе, чөнки Рамазан аенда мөселманнар вакытларын кояш баюны пассив көтеп түгел, ә активлыкны югалтмыйча, дөнья эшен дә башкарып, ихлас гамәл-гыйбадәт тә кылып үткәрергә тиеш.

Ураза тоткан вакытта кайберәүләрнең ач тору сәбәпле ачулары кабара, шул сәбәпле алар якыннарына кычкыра, үзләрен агрессив тота. Әлбәттә, мондыйрак хәл ураза тотуда тәҗрибәсе булмаган, шушы гыйбадәтнең асылын әле аңлап бетермәгән кешеләр белән булырга мөмкин. Сабырлык җитмәү, начар холык, башкаларга тупас мөгамәлә күрсәтү уразаның дәрәҗәсен төшергәнен онытмаска кирәк.

Кояш баеп ахшам намазына азан әйтелгән мәлдә кайберәүләр азан сүзләрен тыңлап, кабатлап тормыйча авыз ача башлыйлар. Динебездә исә азанга карата хөрмәт белдерү тиешле. Шуңа күрә башта азан сүзләрен эчтән кабатлап, азан догасын кылырга, аннан соң гына җимеш кабып яки су йотып авыз ачарга кирәк.

Авыз ачканнан соң, гадәттә, әүвәл ахшам намазы укыла, аннан соң гына табын алдына утырып, ризыкланырга мөмкин. Кайберәүләр: “Әй, намаз вакыты чыкмый әле, өлгерәм!” – дип башта ашарга утыралар, аннан соң гына намаз укыйлар. Әлбәттә, болай эшләргә ярамый. Башта ахшам намазын укып, аннары тыныч күңел белән ризыкланып утыру хәерлерәктер... Шунысы да хак: авыз ачу вакытын артык тоткарларга да ярамас.

Хаталарның тагын берсе – кичке ифтар вакытында артык күп ашау. Көне буе ач торганнан соң ашказанын кинәт тутырып куюдан сакланырга кирәк.

Рамазан аенда авыз ачып ифтар кылгач, ястү намазыннан соң укыла торган тәравих намазына да битараф булмау мөһим. Әлеге сөннәт намазны кылуга салкын карау Рамазан аенда эшләнә торган хаталарның берседер.

Рамазан ае ахырындагы Кадер кичәсенә һәм игътикәф гыйбадәтенә тиешенчә игътибар бирмәү дә хата булып санала.

Шулай итеп, Рамазан аенда без фарызларны үтәп, гөнаһлардан тыелу белән бергә, югарыда искә алынган хаталардан да саклансак иде. Гыйбадәтләребез камил һәм, иң мөһиме - кабул булсын.

Ришат хәзрәт Курамшин,
Кукмара мәдрәсәсе мөдире.

Тәңрем кодрәте

Иң әүвәле Адәмгә (с.г.в)
Уразаны белдергән.
“Аллам хакын хаклыйм”, - дип
Шул заманнан ук килгән.

И изге ай - Рамазан,
Килдең әле яңадан.
Гыйбадәтнең кабуллыгы
Тора бары Алладан.

Тәнгә биреп серле сигнал,
Сәхәрне кичектерми.
Бу - тәңрем кодрәте,
Күпләр белеп җиткерми.

Сәхәрдә җыйган тәгам
Зур сихри көчкә ия.
Пәйгамбәребез дә аны
Иң ләззәтлесе дия.

Озын көне, эссесе
Никтер алар беленми.
Аллам әмере белән,
Ураза да бүленми.

Бәндәләргә җиңеллек
Бирүеңә гел шөкер.
Коръән укып, намаздан соң
Әйтеләдер күп зикер.

Фәүзия Гарипова,
Ютазы районы Байлар авылы.

Яхшы сүз

Борынгы заманнарда бер хикмәт иясеннән дөньядагы иң гүзәл нәрсә турында сораганнар. Ул: “Тел”, - дигән. Тел белән без бик күп матур сүзләр әйтеп, кешеләрне сөендерә алабыз. Тел – ул Аллаһтан бирелгән зур нигъмәт, безнең аралашу чарасы. Тел белән ярату, соклану, кешеләрне юату сүзләрен әйтеп була. Тел белән без сәламнәр, рәхмәтләр җиткерәбез, гафу үтенәбез. Файдалы киңәшләр бирәбез. Тел белән Коръән укыйбыз, изге догалар кылабыз, Раббыбыз Аллаһ турында сөйлибез, зикерләр әйтәбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): “Һәр яхшы сүз – сәдака”, - дигән. Димәк, әйтелгән зикер-догаларыбыз өчен генә түгел, кешеләр белән аралашкандагы һәрбер яхшы сүзләребез өчен дә безгә һәрдаим саваплар язылып бара, әлхәмдүлилләһ.

Шул ук хикмәт иясеннән дөньядагы иң коточкыч нәрсә турында да сораганнар. Һәм ул кабат: “Тел”, - дигән. Ничек итеп тел бер үк вакытта иң гүзәл нәрсә дә, иң куркыныч нәрсә дә була ала соң? Тел белән кешене хәтта үтереп тә була, диләр бит. Ямьсез сүзләр әйтеп, рәнҗетәләр, мыскыллыйлар, үпкәләтәләр. Шуңа тел ул куркыныч та булырга мөмкин. Тел ярдәмендә кешеләр гайбәтләр сөйли, бәхәсләшә, ачуланыша, бер-берсенә Аллаһ яратмый торган әшәке сүзләр әйтеп үрти. Тел – ул безнең корал. Без аны яхшылыкта да, явызлыкта да файдалана алабыз. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) кебек, барлык кешеләр белән күркәм мөгамәләдә булып, сөйләмебезне зикер-догалар белән бизәп, искиткеч күп саваплар эшли алабыз. Һәм шулай ук, нәфесебезгә алданып, тел ярдәмендә искиткеч күп гөнаһлар да эшли алабыз. Бигрәк тә “Ачу хәләтендә башкалар турында фикер җиткерүдән сак булыгыз”, дигән Пәйгамбәребез галәйһиссәләм.

Димәк, тел безне җәннәткә илтүче дустыбыз да була ала, безне җәһәннәмгә өстерәүче явыз дошманыбызга да әйләнә ала.

Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына килеп: “Йә Расүлуллаһ, Аллаһ ризалыгы өчен гомерне корбан итүдән дә саваплырак гамәл юктыр?” – дип сораганнар. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: “Телегезне тыйсагыз, иң зур савапка ирешерсез, сезнең телегез сезне борыныгыздан өстерәп, тәмугка алып баручы”, - дигән.

Телне, чынлап та, тыюы авыр бит. Буш сүзләр сөйләп тә вакытны күп үткәрәбез. “Ишеткән һәр нәрсәне сөйләп йөрү гөнаһ булырга җитә”, дигән Пәйгамбәребез галәйһиссәләм. Шулай ук, сез санап үткән гайбәт, мыскыллау, бәхәсләшү, хурлашу, буш сүзләр сөйләүдән тыш, ялган әйтү, буш вәгъдәләр бирү, мактану, кешеләрне каргау да телебезнең бозыклыгы турында сөйли. Бу бозыклыкны бетерер өчен, безгә нишләргә кирәк соң? - Аллаһ кушканча үз-үзебезне тәрбияләргә кирәк. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең күркәм холкыннан үрнәк алырга тиешбез. Сүз әйткәнче, ныклап уйларга кирәк. Нәфесләребезне дә вакытында тыярга. Кешеләрне яратырга, һәр кешедә иң элек яхшы сыйфатлар күрергә тырышырга кирәк.

Бер кеше акыл иясеннән болай сораган:

– Синең дустың синең хакта шундый сүзләр сөйли икән, әйтимме? - дигән.

– Әйтәсе сүзләреңне иң элек өч иләк аша үткәр, – дип туктаткан аны акыл иясе.

– Нинди өч иләк? – дигән кеше.

– Беренчесе – дөреслек иләге. Дустым әйткәнне син үзең ишеттеңме, бу дөресме?

– Юк, башкалардан ишеттем, - дигән кеше.

– Син әйтәсе сүзләр хаклыкка туры киләме?

– Белмим, - дип җавап биргән кеше.

– Димәк, синең сүзләрең дөреслек иләге аша үтә алмый. Әйдә, икенче иләктән үткәреп карыйк. Икенчесе – изгелек иләге. Син изге ният белән яхшы сүз әйтергә телисеңме? – дип сораган фикер иясе.

– Юк, киресенчә, – дигән кеше.

– Димәк, син, сүзләреңнең дөреслеген дә белмичә, ниндидер начарлык әйтергә җыенасың. Ярар, әйдә соңгы иләкне – файда иләген – кулланып карыйк. Бу сүзләрне ишетү миңа бик кирәкме, моннан берәр нәрсә яхшырамы?

- Юк, файда булмас, - дигән кеше.

- Шулай итеп, син әйтәсе сүзләрдә дөреслек тә, изгелек тә, файда да юк. Нигә алайса аны әйтергә? – дип тәмамалаган фикер иясе.

Алда әйткәнебезчә, тел безне җәннәткә дә, җәһәннәмгә дә кертә ала. Шуңа телеңнең колы түгел, хуҗасы булырга тырышырга кирәк. Мөселман кешесе Аллаһ риза булырдай матур нәрсәләр генә сөйләргә, кешеләрне сөендереп яшәргә тиеш. Яхшы сүз – җан азыгы. Һәрберебез сүзләребезне үлчәп-үлчәп кенә, ДӨРЕСЛЕК, ИЗГЕЛЕК, ФАЙДА иләкләре аша үткәреп кенә сөйләшергә тырышыйк. Шулчак дөньябыз да иминрәк булыр, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр дә ихласлык һәм җылылык белән тулыр, ә үзебез Аллаһ каршында шөкер итүчеләрдән саналырбыз, иншә Аллаһ.

Әлфия Мөдәрисова,
“Хәзинә” клубы мөгаллимәсе.

Коръәни Кәрим укуның файдасы

Тауларда үзенең оныгы белән бер карт кына бабай яшәгән, ди. Ул мөселман булган, шуңа да һәр иртәсен Коръән укуга багышлаган. Оныгы аңа охшарга тырышкан, бабасы ни эшләсә, шуны кабатлап барган.

Бервакыт бу бала: “Бабай, мин Коръән китабын синең кебек укып барырга тырышам, әмма мин аның мәгънәсен аңламыйм. Мин китапны ябу белән, ятлаган әйберләрем башымнан чыга. Шулай булгач, Коръәни Кәрим китабын укудан нинди файда бар соң?” – дип сорый.

Мичкә ташкүмер сала башлаган бабасы, туктап: “Бар, улым, ташкүмер кәрҗинен ал да, елгага төшеп, су алып мен”, – ди.

Оныгы шулай эшли дә: ул кәрҗинне алып, су алып менәргә төшеп китә. Әмма ул тау башына менеп җиткәнче, су кәрҗиннән агып беткән иде инде.

Моны күреп, бабасы елмаеп куя һәм: “Син тизрәк атлап кара”, – дип, оныгын кабаттан су алырга төшереп җибәрә. Монысында инде малай тизрәк атларга тырыша. Әмма тау башына йөгереп менеп җиткәнче, кәрҗин буш була. Бабасына суны кәрҗиндә алып менеп булмаганлыгын хәбәр иткәч, малай чиләк артыннан китә. Бабасы моны күреп: “Әмма миңа бер кәрҗин су кирәк, миңа бер чиләк су кирәкми. Син бар көчеңне куеп эшләргә теләмисең генә”, – дип каршы төшә.

Оныгы бу хәлнең мөмкин түгеллеген исбатлар өчен, кабаттан елга буена төшеп китә. Ул кәрҗине белән су тутырып ала да, бар көченә бабасы янына чаба башлый. Әмма менеп җиткәнче, су агып беткән була.

Хәленнән тайган малай: “Менә, бабай, әйттем бит мин сиңа – болай булмый”, – дип нәтиҗә ясап куя.

“Син моны мәгънәсез дип уйлыйсыңмы? – дип сорый бабасы. – “Кәрҗингә карап ал әле”.

Оныгы кәрҗингә карагач, ташкүмердән каралып беткән кәрҗиннең эчтән дә, тышкы яктан да чистарганын күреп ала.

“Балам, Коръән укыган вакытта менә ниләр була. Син аны укыган вакытта аңламаска да, истә дә калдырмаска мөмкинсең. Әмма ул сине эчке яктан да, тышкы яктан да үзгәртергә сәләтле. Менә шул рәвешле Аллаһы Тәгалә безнең тормышыбызны да үзгәртә”.

Дога шифасы

Язгы кояш җанны сугара, һәр минуты, һәр сәгате сәгадәт, олы куаныч була алырлык очрашуны тоеп ашкынам. Рухымны, җанымны савыктырып торучы илаһи көч мине үзенә тарта. Уйларым, хисләрем бөтерелеп-бөтерелеп балачагыма кайтаралар. Гомере буе кешеләргә итагатьлелек, әдәплелек өлгесе булып, мөселман кануннарын саклап, ярдәм кулын сузып яшәүче әбекәем... Йөрәгә нечкә кылдан нечкәрәк булган әбекәем янында ниндидер җылылык, җан тынычлыгы тоясың. Күзләрендә кояшның тәүге нурлары белән язылган дога юлларын укыгандай буласың. Кояш чыкканчы торып, иртәнге намазга Аллаһы каршына тезләнгәндә язылгандыр ул күзләргә дога юллары. Әйе, үз динен, иманын саклый алган кешедә рухи җылылык булмый калмый шул.

Мин кечкенә. Әбекәем белән чишмә янына киләбез. Челтер-челтер ташларга сыенып моң агыла кебек. Кыялардан сыкрап сихри аһәң чыңлый. Әбием миңа дога юлларын кабатлый, ә мин ятларга тырышам. “Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Кулһүаллааһү...” Без кабатлаган дога юллары ап-ак каеннарга барып сыена да, акрын гына ак болытларга күтәрелә дә, сихри аһәңгә әверелеп, ак нур булып, саф чишмә суларына сыенып сихри моңга әйләнә кебек. Әбием миңа табигать, бөек көчләр, әдәплелек, кешелеклелек... турында сөйли. Әнә каршыбызга, 5-6 яшьлек кызын җитәкләп, авылыбызда китапханәче булып эшләүче Мәдинә апа килә. Аның сагышлы күзләре, борчулы йөзеннән күңеле тыныч түгеллеген күреп була. Әбекәем алдында кыенсыну, бушанасы, тынычланасы килү теләге дә чагыла кебек... Әйе, аның тормышы җиңелдән түгел шул. Тормыш иптәше көн-таң атса исерек. Иң авыры, иң куркынычы - Мәдинә апага кул күтәрүе, өйләреннән куып чыгаруы. Бер генә ярдәм итәр кешесе дә юк шул.

“Түтекәем, сезгә бер үтенечем бар иде, тыңламассызмы икән”, - диеп, бик кыенсынып кына башлады ул сүзен. Һи, минем әбиемме, тыңлый, билгеле, күпме кешегә ярдәм итте ул, санап бетерерлек түгел.

“Кызымны берәр атнага карап тора алмассызмы, авырып киттем бит әле”, - дип эйтеп өлгермәде, әбием бик тиз генә ризалыгын бирде. Шул ук көнне, нәни кыз Сания бераз ияләшә төшсен диеп, Мәдинә апа да әбиләремдә кунды. Кызының бөтен нәрсәдән куркуы, инде нәрсә эшләргә белмәве турында кат-кат борчылып сөйләде. Икенче көнне иртүк Мәдинә апа хастаханәгә китеп барды. И елады да инде нәни кыз. Әбекәем өф-өф итеп кенә торды аны. Төнгә кадәр утны сүндермичә үз кочагында иркәләп-назлап юатты. Тәмледән-тәмле ризыклар пешерде.

Әбием нәни кызга: “Кызым, кешеләрне саклый, яклый торган бер дога бар, шуны ятласаң, куркулар да бетә”, - диеп аңлатты. Саниянең күзләрендә өмет чаткылары кабынып киткәндәй булды. “Нәрсә соң ул дога?” - диеп әбекәйгә килеп сыенды.

Куркудан котылу теләге шулкадәр көчле идеме, белмим, тиз ятлады ул “Аятелкөрси”не. Әкренләп берүзе тышка да, өйалдына да чыгып керә. Әллә ныклап ияләшү, әллә чынлап та зур ышану, инану көче сабый күңеленә тыныч иңдерде. Көнгә берничә тапкыр яхшылап юына да, утырып “Аятелкөрси”не укый һәм йөгереп ишек алдына чыга, тыныч эйный...

Әнисе кайткач та: “Әни, мин китмим, әбием белән яшим”, - дип елады, карышты. Әйе, исерек әтисе янына кайтасы килмәде. Иң мөһиме - сабый күңеленә ак нур кунды, иман нуры. Мәдинә апа кызы Сания белән әбием янына бик еш киләләр. Икесе дә яңадан-яңа догалар өйрәнәләр.

Сабыйлар күңелендәге бушлыкны догалар, иман нуры белән тулыландыру, үз-үзен дә аңлый алмаган кешеләр җанын сафландыру, гомумкешелек кыйммәтләрен кайдан эзләргә икәнлеген, һәр кеше өчен мөһим булган кыйбланы табарга юнәлеш бирүче әби-бабайлар, әти-әниләр бик кирәк шул.

Р. Авзалова.

Саулыгым – байлыгым

Карлыган яфрагы

Карлыган яфрагы витаминнарга һәм файдалы элементларга бай. Аның составында эфир майлары һәм фитонцидлар, С витамины күп. С витамины, антиоксидант ролен башкара, организмны картаюдан һәм авырулардан саклый.

Карлыган яфракларын яшь һәм чиста булганда җыю дөрес. Иң яхшысы - май ахырында җыю. Шулай ук кайбер чыганаклар аны июнь ахырына кадәр җыярга ярый дип язылган.

Бу яфракны кара чәйгә өстәмә буларак та салалар. Болай эшләгәндә, гадәти чәйгә хуш ис өстәлә. Чәйнең файдасы да арта. Шулай ук аны аерым термоста да төнәтәләр. Грипп вакытында карлыган яфрагыннан чәй организмны ныгыту чарасы булып тора. Чәен әзерләү өчен, ике бал кашыгы киптерелгән яисә яңа өзелгән карлыган яфрагына бер стакан кайнар су салып, өстен каплап торабыз. 10-15 минуттан чәй әзер.

Әлеге чәйне цистит, пиелонефрит, кан басымы авырулары, пародонтоз вакытында, шулай ук иммунитетны ныгыту өчен һәм антисептик чара буларак та кулланалар.

Карлыганның яшь яфраклары тире авыруларыннан, төче авыруыннан (золотуха), салкын тигәндә, бөердә ташлар булганда, ревтамизмнан, буыннар авыртуыннан шифалы. Кара карлыган җимешләре согы һәм шикәр кушып ясалган сиробы ярдәмендә тамакка салкын тиюне, үпкәдәге гыжылдау тавышын, бума ютәлгә, эчәклектәге авыруларга каршы көрәшеп була. Шулай ук яртылаш гөлҗимеш согы белән кушып эчәргә мөмкин.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР
Баш мөхәррир
Муллагалиева А. Г.
Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы: 1430
Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
17 май 16 сәг.
фактта 17 май 16 сәг.
Бәясе ирекле